**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

“24” нче декабрь 2018 нче ел № 103

**“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2018 нче елның 1 нче октябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары кадрларын һөнәри әзерләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 79 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”**

2013 нче елның 5 нче апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 44-ФК номерлы Федераль канун нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2018 нче елның 1 нче октябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары кадрларын һөнәри әзерләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 79 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2018 нче елның 1 нче октябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары кадрларын һөнәри әзерләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 79 номерлы карарына кушымтаның 3.1, 6.8 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- “Җирле үзидарә органнары кадрларын яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү үткәрелгән конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла, җирле үзидарә органнары кадрларын яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү графигы төзелә, алар нигезендә графта күрсәтелгән срокларда укырга җибәрү гамәлгә ашырыла”;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2018 нче елның 1 нче октябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары кадрларын һөнәри әзерләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 79 номерлы карарына кушымтаның 6.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- “Укуга гаризалар (тәкъдимнәр) нигезендә муниципаль заказ төзелә, ул 2013 нче елның 5 нче апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 44-ФК номерлы Федераль канунда һәм дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итүгә юнәлдерелгән гамәлләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында башка норматив хокукый актларда каралган тәртиптә урнаштырыла.”;

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында””Интернет” мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль**
**районы Башлыгы** **Козлов В.М.**